Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Кубас авылы җирлегенең Старое Иванаево авылы торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Кубас авыл җирлеге составына керүче Старое Иванаево авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында
КАРАР

2019 елның 12 ноябре № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2019 елның 12 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлегенең Старое Иванаево авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, I төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- Старое Иванаево авылы урамнарын төзекләндерү (вак таш, грунтлау һәм вак таш салу)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 82 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 42 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 42 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлегенең Старое Иванаево авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлегенең Старое Иванаево авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, I төркем инвалидларыннан тыш, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- Старое Иванаево авылы урамнарын төзекләндерү (вак таш, грунтлау һәм вак таш салу) буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлегенең Старое Иванаево авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлегенең Старое Иванаево авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Старое Иванаево авылы урамнарын төзекләндерү (вак таш, грунтлау һәм вак таш салу).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кубас авыл җирлеге башлыгы _________________ Н. С.Логинова